ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 28 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 5, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 51 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемдә «халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә» сүзләрен «халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяда:
а) исемдә «халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә» сүзләрен «халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга;
б) беренче абзацта «халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә» сүзләрен «халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга;
в) 2 пунктта «халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениесе» сүзләрен «халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән дәүләт учреждениесе (алга таба – эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе)» сүзләренә алмаштырырга;

3) $2^1$ статьяда:

а) исемдә «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә» сүзләрен «Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән тапшырылган вәкаләтне гамәлгә ашыручы органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән тапшырылган вәкаләтне гамәлгә ашыручы органы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) хезмәт, эш белән тәэмин итү, альтернатив граждан хезмәте өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән тапшырылган вәкаләтне гамәлгә ашыру турында хисапны, шул исәптән субвенция акчаларын тоту турында хисапны, үз вакытында тапшыруны тәэмин итү;»;

в) 2 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә законнар ярдәмендә җайга салу, халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнарның үтәлешен Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм рәвешләрдә тикшереп торуны гамәлгә ашыру;»;

г) 3 өлештә:

1 пунктта:

беренче абзацта «халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә» сүзләрен «халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эшсез гражданнарга индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәвенә куелганда, төзелә торган юридик зат дәүләт теркәвенә куелганда, крестьян (фермер) хуҗалыгы дәүләт теркәвенә куелганда, физик зат һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органында исәпкә куелганда бер мәртәбә бирелә торган финанс ярдәменең күләмен һәм аны бирү тәртибен;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эш эзләүче гражданнарга, эшсез гражданнарга эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күчкәндә (күченеп киткәндә) финанс ярдәме күрсәтү күләмен һәм тәртибен;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген), региональ дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) әлеге төрен оештыруга һәм гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне исәпкә алып, оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен;

гражданнарга эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча вакытлыча характердагы түләүле эшләрдә яисә түләүле җәмәгать эшләрендә катнашу чорында һәм (яисә) эш бирүчеләргә мондый эшләрне оештырганда финанс ярдәме күрсәтү очракларын һәм тәртибен;

һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм фәнни белгечлекләр буенча Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укырга кабул итүнең гомуми контроль саннары күләмен һәм һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм фәнни белгечлекләр буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль берәмлекләрнең җирле бюджетлары бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укырга кабул итүнең гомуми контроль саннары күләмен килештерү тәртибен;

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 1 өлешендә каралган махсус чараларны гамәлгә ашыру тәртибен;»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;»;

3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт ярдәме чараларын финанс белән тәэмин итү, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген матди-техник һәм финанс белән тәэмин итү;»;

түбәндәге эчтәлекле $4^2$ – $4^4$ пунктлар өстәргә:

«$4^2$) инвалидларны һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен яраклырак аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау тәртибен билгеләү яисә мондый гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары санын билгеләү;

$4^3$) гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү һәм Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү буенча еллык чаралар планын раслау;

$4^4$) рәсми булмаган мәшгульлеккә каршы көрәш буенча Татарстан Республикасы ведомствоара комиссиясен төзү;»;

д) $3^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$3^1$. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эш бирүчеләргә хезмәт ресурсларын җәлеп итүдә ярдәм күрсәтү максатларында хезмәт ресурсларының мобильлеген арттыру буенча региональ программаны (алга таба – региональ программа) раслый. Региональ программа хезмәт ресурсларын җәлеп итүгә ихтыяҗы булган эш бирүчеләр белән бу программада катнашу турындагы килешүләрне, шулай ук эш бирүчеләргә Россия Федерациясенең ике һәм аннан да күбрәк субъектыннан хезмәт ресурслары җәлеп итүдә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары арасында төзелә торган регионара килешүләрне (әлеге регионара килешүләр төзелгән очракта) исәпкә алып эшләнә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан түбәндәгеләр билгеләнә:

1) вазыйфалар, һөнәрләр, белгечлекләр буенча эшләр башкару өчен региональ программаны гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткәрләр җәлеп ителә торган вазыйфалар, һөнәрләр, белгечлекләр исемлеге;

2) эш бирүчеләрне региональ программада катнашу өчен сайлап алу тәртибе һәм критерийлары һәм алар белән күрсәтелгән программада катнашу турында килешүләр төзү тәртибе;

3) эш бирүчеләрне региональ программада катнашучылар арасыннан төшереп калдыру һәм күрсәтелгән программада катнашу турында алар белән килешүләрне өзү тәртибе һәм нигезләре;

4) региональ программада катнашучы эш бирүчегә эшкә урнаштыру өчен Россия Федерациясенең башка субъектларыннан хезмәткәрләр җәлеп итү максатларында финанс ярдәме күрсәтү тәртибе һәм шартлары;

5) региональ программа кысаларында эшкә урнаштыру өчен Россия Федерациясенең башка субъектларыннан хезмәткәрләр җәлеп итү максатларында бирелгән финанс ярдәме чараларын региональ программада катнашучылар арасыннан төшереп калдырылган эш бирүчеләр тарафыннан кире кайтару тәртибе һәм шартлары;

6) хезмәт мөнәсәбәтләрен вакытыннан алда туктаткан яки алар белән мондый мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе законнарында каралган дисциплинар хокук бозулар яисә башка гаепле гамәлләр кылуга бәйле рәвештә туктатылган хезмәткәрләр тарафыннан региональ программа кысаларында бу хезмәткәрләргә финанс ярдәме күрсәтүгә фактта тотылган акчаларны кире кайтару тәртибе һәм шартлары.»;

е) $3^2$ өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

ж) $3^3$ өлештә:

4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә дәүләт ярдәме чараларын эшләргә һәм аларны бирү тәртибен билгеләргә.»;

з) 4 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнарны куллану практикасын гомумиләштерү һәм аны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Татарстан Республикасында хезмәт базарына мониторинг уздыру;»;

$4^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$4^1$) үзе билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы карамагындагы эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнарны бозуларны бетерү турында, гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту хакында мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү хокукы белән тикшереп тору;»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) яраклы эш эзләү максатларында гражданнарны теркәү, шулай ук эшсез гражданнарны теркәү;»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә төп дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү, аларга түбәндәгеләр керә:

гражданнарга яраклы эш эзләүдә ярдәм итү, анкета тутыруда ярдәм күрсәтүне дә кертеп;

14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытта вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру;

эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру;

түләүле җәмәгать эшләре уздыруны оештыру;

эш эзләүче гражданнарны, эшсез гражданнарны социаль адаптацияләү;

гражданнарга һөнәри эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәри уку узу, өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;

эшсез гражданнарга психологик ярдәм;

башка җирлектә укуны да кертеп, эшсез гражданнарның һөнәри уку узуын, өстәмә һөнәри белем алуын оештыру;

эшсез гражданнарга эшкуарлык эшчәнлеген һәм керем китерә торган башка эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлауга ярдәм итү, индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәвенә куелганда, төзелә торган юридик зат дәүләт теркәвенә куелганда, крестьян (фермер) хуҗалыгы дәүләт теркәвенә куелганда, физик зат һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органында исәпкә куелганда бер мәртәбә бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп;

эш эзләүче гражданнарга, эшсез гражданнарга эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күчкәндә (күченеп киткәндә) ярдәм итү;

мобилизация буенча хәрби хезмәт яки «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә төзелгән контракт буенча хәрби хезмәт узуын тәмамлаган гражданнарны яки «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законда каралган ихтыярый формированиедә булу турында төзелгән контрактының гамәлдә булуы туктатылган гражданнарны, шулай ук «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 5 һәм $5^1$ пунктлары нигезендә аларның гаилә әгъзаларына кертелә торган гражданнарны өстенлекле рәвештә эшкә урнаштыруга ярдәм итү;

инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәткәндә булышуны оештыру;

эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлап алуда ярдәм итү;

вакансия һәм өйрәнчек эш урыннары ярминкәләре оештыру;

эш эзләүче гражданнарны, эшсез гражданнарны һәм эш бирүчеләрне профильләштерү буенча махсус чаралар оештыру һәм үткәрү;

Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы хәл, гражданнарның социаль-хезмәт хокуклары, эш белән тәэмин итү рәвешләрен үстерү турында мәгълүмат бирү.»;

7 – 9 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнар бозылу ачыкланганда, аның сәбәпләрен бетерү һәм гражданнарның бозылган хокукларын торгызу буенча чаралар күрү;»;

$10^2 – 10^9$ пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле $10^{10}$ һәм $10^{11}$ пунктлар өстәргә:

«$10^{10}$) эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының гражданнарны эшкә урнаштыруда һәм (яисә) хезмәткәрләр сайлауда ярдәм итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләтнеке булмаган оешмалар белән, эш белән тәэмин итү буенча хосусый агентлыкларны да кертеп, үзара эшчәнлек тәртибен билгеләү;

$10^{11}$) хезмәт базарында ихтыяҗ булган һөнәрләр, белгечлекләр исемлеген раслау;»;

и) 8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында Россия Федерациясе законнары белән җайга салына.»;

к) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә халыкара хезмәттәшлекнең төп юнәлешләре буенча халыкара оешмалар, чит илләрнең дәүләт органнары, чит илләрнең хөкүмәтнеке булмаган оешмалары, шулай ук башка оешмалар белән үз компетенцияләре чикләрендә үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыралар.»;

4) 3 статьяда:

а) исемдә «халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә» сүзләрен «халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә:

беренче абзацта «халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә» сүзләрен «халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «яраклырак һөнәрләр буенча эш урыннарын» сүзләрен «яраклырак аерым эш төрләрен (профессияләрне)» сүзләренә алмаштырырга;

5) $3^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$3^1$ статья. **Эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категорияләренә социаль түләүләрне гамәлгә ашыруны мәгълүмати тәэмин итү**

Әлеге Закон нигезендә эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категорияләренә социаль түләүләрне гамәлгә ашыру турындагы мәгълүмат «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла. Күрсәтелгән мәгълүматны «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру һәм аның белән танышу «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

6) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Татарстан Республикасында эш белән тәэмин итү хезмәте органнары**

Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм Россия Федерациясе вәкаләтен гамәлгә ашыру чараларын үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм дәүләт идарәсе функцияләрен гамәлгә ашыра торган органы һәм эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре гамәлгә ашыра.»;

7) 5 статьяда:

а) исемдә «халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә» сүзләрен «халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә» сүзләрен «халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 3 пунктының «г» пунктчасындагы дүртенче – җиденче, унынчы, унбишенче – унҗиденче абзацларыннан, «д» – «ж» пунктчаларыннан, «з» пунктчасындагы унынчы – егерме сигезенче, утыз беренче – утыз дүртенче абзацларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пунктының «г» пунктчасындагы дүртенче – җиденче, унынчы, унбишенче – унҗиденче абзацлары, «д» – «ж» пунктчалары, «з» пунктчасындагы унынчы – егерме сигезенче, утыз беренче – утыз дүртенче абзацлары 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 12 декабрь
№ 93-ТРЗ